


Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ* ФЕВРАЛЬ * 2016 КАЗАН

3



Виталий ФЕОКТИСТОВ

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Вашингтонда, Ак Йорт каршында, рубль белән ипотекага кредит алган американнарның демонстрациясе булып узды.
- Алманиядә, хатын-кызларны көчләүдә гаепләнгән мигрантларга бушлай җенси тәрбия курслары ачылачак.
- Чираттагы Бөтенрәсәй икътисадый форумы Псков өлкәсенең Дно станциясендә үткәреләчәк.
- Сәламәтлек саклау министрлыгы, дуңгыз гриппының спонсоры дип, медицина битлекләре эшләүчеләрен таныган.
- Экспертлар, кризис вакытында кече бизнес ачар өчен, зур бизнес сатып алып, бераз көтеп торуны тәкъдим итәләр.
- Америка киноакадемиясенә, Панкратов-Черныйга Оскар премиясен бирергә теләмәвендә расизм чаткыларын күреп, шип белдерделәр.
- Мәктәпләрдә яңа дәресләр барлыкка килүе мөмкин – Е-кодлы ашамлыкларны һәм банк договорларын укый алу кагыйдәләрен өйрәнү.
- Мәгариф министрлыгында БДИ (Бердәм Дәүләт имтиханы) шаһитлар сектасы барлыгы ачыкланган.
- Европа кибетләрендә сатуга целлюлитлы Барби курчаклары һәм "сыра корсаклы" Кен чыккан.
- Талау сигналы буенча килгән полиция наряды, фатирда ЖКХ квитанцияләре тотып утыручы бер әбигә тап булганнар.
- Метеорологлар, ризасызлык белдереп, баш күтәргәннәр һәм, әгәр дә хезмәт хакларын күтәрмәсәләр, бик көчле бозлавык булдырачакларын әйтеп куркытканнар.
- Фатирында опера ариясен башкарган берәүне кемнәрдер үтерә дип белгәннәр.
- Эшсез торалмый торган бер эшсезне, эшкә урнаштыру бюросын пыртуздырганы өчен, хезмәт белән төзәтү колониясенә озатканнар.
- Бер төн эчендә кулинария китабын ашап бетергән кеше хастаханәгә эләккән.
- Түбән Камада, түбәдән асылынып торучы боз сөңгесе йорты-ние белән мәтәлеп төшкән.
- Водопроводчы М. эшен шулхәтле ярата ки, хәтта китәргә дә өлгерми.
- Пенсионер Хәдичә әбинең чутлавы буенча, фахишәләрнең һәм наркоманнарның саны трамвайдагы урыннар санына төп-төгәл туры килә.



ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел Дәүләт Думасы депутатларының берсе балаларыбызга... балачакны кайтару турында тәкъдим кертте! Чынлап та, мәктәптә аларга бик зур йөк өелгән бит. Балаларны беренче сыйныфтан ук ЕГЭ белән куркыта башлыйлар. Саф һава сулау, спорт белән шөгыльләнү һәм йокыларын туйдыру урынына алар тәүлек буе диярлек дәресләр белән мәшгуль. Ә өй эшләрен репетиторсыз ерып чыга торган түгел...

Д. ХӘБИБРАХМАНОВА

КАЗАН

– Өй эшләрен укытучылар укучыларга дип бирә, – диде Шомбай ага, хатны укып чыккач, **– ә бөтен авырлыгы ата-аналар җилкәсенә төшә...**



Виктора СКРЫЛЁВ рәсемнәрен 20нче биттә карагыз.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Россия – тотылмаган караклар һәм мәңгелек киләчәктәге бәхет иле.

Яхшы көлүче соңгы тапкыр көлә.

Иң кара китап – Кызыл китап.

Халыкның авызын томаласаң, ул уйлый башлый.

Тигезлек математикада гына мөмкин.

Күчү заманы катлаулыгы: элекке хакыйкать инде ялганга әйләнде, ә яңа ялган хакыйкатькә әйләнергә өлгерми.

Мәңгелек кебек бернәрсә дә ашыктырмый.

"Бөтен кешенең дә шулай", "Заманасы шундый" кебек сүзләр белән без үзебезнең төпсезлегебезне акларга тырышабыз.

Үзеңне үзгәрткән очракта гына үткәннәр үткәндә кала.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды).



Вячеслав БИБИШЕВ

Нияз БИШБАЛТА

АЛЛАРЫН АЛГА МАНАМ

Китәм дисең син, бай дустым,
Чит илләргә? Кайларга?
Акча калдыр әле бераз,
Эшләремне җайларга.

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Кытлык чоры дәвам итсә,
Шып-шыр ялангач калам.

Китәм дидең, читкә киттең,
Вилла сатып алырга,
Болгавыр чорда кешечә,
Бераз яшәп калырга.

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Хөкүмәт пинсе бетерсә,
“Арт”ка утырып калам...

Китәм дидең, китеп бардың,
Байгуралар янына,
Милкең алынды, үзеңне
Полиция “сагына”...

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Кем уйлаган: картлык җитеп,
Шушындый көнгә калам?..



Дәүләт Думасына төпле, акыллы кешеләрне сайларга кирәк, «мумушник»ларны түгел. Сөйли һәм дәлилләп яклый белә торганнарны. Ә бездә ничек: сайлана да, аннан соң му-му, бе-бе, ме-ме...

**Фәрит Мөхәммәтшин,
Татарстан Дәүләт Советы Рәисе**

Без беркайчан да акчаны суга салмадык, ләкин бу ел үзенчәлекле...

**Илсур Метшин,
Казанның шәһәр башлыгы**

Районнарда эшмәкәр хакимият рөхсәтеннән башка төчкерә дә алмый...

(ТРның кече һәм урта бизнес ассоциациясе конференциясендәге чыгышлардан)

Безнең чиновниклар – намуслы кешеләр. Утырган урыннары мөмкинлек биргән кадәр...

(редакциягә килгән хаттан)



Владимир ИЖБОЛДИН

Мунча хәлләре

Күз алдыгызга китерегез, хөрмәтле укучым, сез – эшмәкәр, ди. Бизнесыгыз зур булмаса да, азмыкүпме табыш бирә, ә кешеләргә файда китерә. Сез салымнарны һәм аренда өчен вакытында түләп барасыз. Һәм көннәрдән бер көнне, бинаны арендалау турындагы килешенүне озайтырга вакыт җиткәч, сезне тупас рәвештә эш урыныгыздан куып чыгаралар.

Яшен Үзәндә яшәүче өч бала атасы һәм эшмәкәр Дмитрий Глазков нәкъ шундый хәлдә калган. Ул биш ел дәвамында Жуков урамында урнашкан ташландык мунча бинасында ике бүлмә арендалаган. Җиренә җиткереп ремонт ясаган, буфет һәм парикмахерская ачкан. Узган елның ахырында аренданың срогы чыккан, һәм эшмәкәр аны озайтырга булган. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасында аңа аңлатканнар: моның өчен башта аренда килешенүенең гамәлдән чыгарылуы турында актка имза куярга кирәк. Бизнесмен шулай иткән дә. Тик соңыннан бик үкенгән...

Икенче көнне үк болганчык туксанынчы елларга охшаган вакыйгалар башланган. Иртән парикмахерскаяга таза җилкәле дүрт егет килеп кергән. Үзләрен алар МУП «Горзеленхоз»ның... иминлек хезмәте хезмәткәрләре дип таныткannar. «Бүлмәләр печатьләп куела, – дигән алар. – Бүгеннән алар «Горзеленхоз» милке булып санала!» Һәм бүлмәләрдә электрны өзә башлыйлар. Шушы вакытта куркынган парикмахер кызлар чакырган Глазков кайтып керә. Ул шунда ук кулына эләккән «болгарка» белән милкен якларга ташлана.

Бу – ярсу рейдерларның канын бераз суыта, ләкин тынычландырмый. Глазковка МУП башлыкларының имзалары белән бүлмәләрне бушатуны таләп иткән күпсанлы хатлар килә башлый. Эшмәкәр дә йоклап ятмый – тиешле инстанцияләргә басып алучылар турында гаризалар язып җибәрә.

Бу каршы торуның нәтиҗәсе: ике як та Яшел Үзән Башкарма комитетында очраша. Эшмәкәргә каршы чыккан якның дәлилләре каен себеркесе кебек гади иде: Глазков арендалаган бүлмәләр мунча бинасындагы шәһәргә карый икән, димәк, ул МУП карамагында булырга тиеш.

Ләкин Глазков мөрәҗәгать иткән монополияләргә каршы көрәш хезмәте белгечләренең фикере башка төрле иде. Алар конкуренция законы бозылу турында белдерәләр. Шуңа күрә Яшел Үзән хакимиятенә бу милекне «Горзеленхоз» карамагыннан алыну чарасын күрергә таләп куела.


Бу вакыйга көтелмәгәндә менә шулай тәмамланды! Мунчадан рейдерларга каршы чыгарга курыкмаган эшмәкәргә түгел, ә фикер йөртүләре һәм гамәлләре туксанынчы еллар кануннарыннан арынып җитмәгән закон бозучыларга китәргә туры килде.

Айдар СУБАЕВ


Анатолий РАДИН



Валентин ДУБИНИН



КАРА АЛТЫН ЗӘХМӘТЕ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Валентин ДРУЖИНИН



Виталий ПОДВИЦКИЙ



• • •

– Өйләнсәң өйләнергә кирәк йә матур кызга, йә шәп пешекчегә.

– Ләкин бу мөмкин нәрсә түгел!

– Нигә?

– Бу бит инде ике хатынлылыкка керә!

• • •

– Яратасыңмы мине?

– Асылдан язып.

– Минем өчен үләр идеңме?

– Юк, кадерлем, минем мәхәббәтем үлемсез!

• • •

Бензин заправкасында акция: “Бензинны багыгызга тутырып салсагыз, 5 литрны бушлай бирәчәкбез!”

• • •

Электрикның эшен күзәтеп торганда электр чыбыгының ике төргә бүленгәнен аңлыйсың – “шунысы микән” һәм “ах, анасын сатыйм”.

• • •

Берәүләрнең тормышы зебра кебек полоса-полоса булса, минеке шакмак-шакмак – шахматтагы сыман... Менә шунда әле королева белән яшим, әле пешка белән. Күбрәк, әлбәттә, ат сыман яшәргә туры килә.

• • •

– Алё, бу телефон буенча сексмы?

– Әйе.

– Ә ни өчен пышылдап кына?

– Оныклар йоклый...

• • •

– Сез инглизчә сөйләшәсезме?

– Словарь белән генә. Кешеләр белән сөйләшергә әлегә оялам.

• • •

Кыз сораштыра:

– Әнә тегендә сезнең нинди открыткалар ул? Юк, анысы түгел, әнә тегесе, йөрәк сурәте ясалганы?

– “Минем бердәнберемә”.

– Бирегез әле шундыйны, алтыны...

• • •

– Ничек анда синең мәңге айнымас ирең? Тагын акчасын теләсә кайда эчеп бетереп йөримe?

– Юк. Мин аның белән ныклап утырып сөйләштем, хәзер ул эчми, тартмый, теләсә кайда теләсә кем белән эчеп тә йөрми. Әнә, тыныч кына реанимациядә ята...

• • •

Бер кирпечтән йорт җиткереп буламы? Була. Бу серне сезгә бары тик ЮХИДИ инспекторы Хәсәншин гына чишә ала.

БЕЗНЕҢ КЫЗЛАР

(негр халык җыры)

...Басуларда банан гөрләп үсә,
Баобаблар чәчәк аталар.
Бамбук тырма салып иңнәренә,
Безнең кызлар эшкә баралар.


Җилфердәтә сары яулыкларын
Кайнар чүлнең сәмум җилләре.
Нинди кызлар үсә Нил буенда –
Бигрәк нечкә инде билләре...

Кокос җыеп, өчәр п(ы)лан үтәп,
Талып кайта алар кырлардан.
Ләкин яшьлек үзенекен итә –
Яңгырый чүл дәртле җырлардан!

...Тамтам кагып, егетләре көтә,
Янып тора дәрттән күзләре.
Безнең кызлар – тыйнак кызлар алар:
Алсулана кара йөзләре...

Ринат АБЗАЛОВ





ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

ЧӘЧӘКЛӘР! ЧӘЧӘКЛӘР? ЧӘЧӘКЛӘР...

Хәмис Гарипов:
Җир йөзендә чәчәкләр күп,
Лилияләр, Ландышлар...
Шул чәчәкләргә ник бәйле
Икән безнең язмышлар?

Алмаз Хәмзин:
Җир йөзендә күбәләк күп,
Чәчәк кочып очалар...
Без дә шулай кочар идек –
Алиментка кысалар.

Х. Г.:
Матур чәчәк кызыктыра,
Куллар шуңа сузыла.
Шул чәчәкләргә бәйләнеп
Күпме тормыш бозыла?

А. Х.:
Бәйләнмә аңа, сузылма,
Ярат кына, өйләнмә!
Кызыкканга кызып китеп
Өйләндем дип, сөйләнмә!

Х. Г.:
Язмышны үзгәртеп булмый,
Языла ул туганда.
Шау чәчәкле гөлдәй бәхет
Телик һәрбер туганга!

А. Х.:
Язмышны үзгәртеп була,
Язылмый ул туганда –
Өйләнгәч тә үзең әйбәт,
Хатын "чәчәк!" булганда!

ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



• • •

– Рәхмәт, доктор! Бер атна элек импотенциядән биргән таблеткаларыгыз искиткеч булып чыкты!

– Ә хатыныгыз канәгатьме соң?

– Белмим, минем әле өйгә кайтып җиткәнем юк.

• • •

Хирург авыруның рентген сурәтен карый.

– Сезгә ничә яшь?

– Тиздән кырык тула.


– Белмим, белмим... Бер дә кырык тулулар кебек күренми әле монда...



Александр АЛЁШИН




Игорь КИЙКО





Виктор ФЁДОРОВ



САЙЛАУ ХИКМӘТЛӘРЕ

(Агитатор язмалары)

Бүген беренче тапкыр фатирлар буйлап агитацияләп йөрдем. Көннең нәтиҗәсе: 17 тапкыр сүгенеп куып чыгардылар, 8 тапкыр баскычтан этеп төшерделәр, 5 тапкыр өскә эт җибәрделәр, 3 тапкыр 100 грамм салып бирделәр, 1 тапкыр өйләнергә тәкъдим ясадылар. Имза җыйдым. Уф-ф-ф...

Бүген листовкалар ябыштырып йөрдем. Кләй беткәч, калган листовкаларны пәрәмәч сатучыга бирдем. Пәрәмәчләрен төреп сатарга. Шулай итеп, тагын берничә йөз кеше безнең партиянең программасы турында беләчәк!

Агитация белән электричкаларда йөрдем. Хәерче дип уйладылар, ахрысы. Өч имза һәм тиеннәр белән кырык җиде сум акча җыйдым...

Күрше карчыкны үгетләдем. Өеннән чүп чиләген чыгарып түктем. Безнекеләр өчен тавыш бирергә риза булды!

Тагын имза җыярга урамга чыгарып җибәрделәр. 15 имза җыймыйча кайтма, диделәр. Шәраб кибете янына киттем. 15 имза миңа 5 шешә аракыга төште. Штабта мактадылар, тик аракыга тоткан акчаны бирмәделәр. Кабахәтләр!

Партия съездында булдым. Берече тапкыр якыннан үз күзләрем белән юлбашчыны күрдем. Ул миңа күз кыскан кебек тоелды! Кайчан да булса бу турыда балалар һәм оныкларыма сөйләрмен әле... Фуршетта берәр стакан газлы су гына биргәннәре турында сөйләп тормам инде... Ә үзләре кашыклап икра ашадылар!

Берсекөнгә сайлаулар. Сайлау участогына күзәтүче булып барам. Игътибарлы һәм уяу булырга куштылар – конкурентларның артык бюллетеньнәр салуы бар. Миңа да бер дистә бирделәр, сиздермичә генә салырсың, диделәр.

Сайлаулар алдыннан төне буе керфек какмадым. Уйландым, уйландым... һәм аңладым: иң мөһиме – җитте кемнеңдер агитаторы булып йөрергә! Үз партиямне оештырырга вакыт!

(Шушы урында язмалар өзелә)

Язмаларны редакциягә Антон МАКУНИ китерде.


Валентин ДУБИНИН



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Александр ДИМИТРОВ



Максим СМАГИН



Валерий ТАРАСЕНКО





БЕРӘҮГӘ ДҮРТ


Кабынып киткән санкцияләр сугышында илебезнең авыл хуҗалыгына зур өметләр баглыйлар. Имеш, авыл бу юлы да безне уңайсыз хәлгә куймас һәм шәһәрдә яшәүчеләрне азык-төлек белән тәэмин итәр. Ләкин бер сорау туа: өзлексез барган реформалар, тәҗрибәләр һәм үзгәртеп корулардан соң анда күпме игенче калды икән? Җавапны Росстат мәгълүматлары бирә. 2016 елның 1 гыйнварына Татарстанда барлыгы 3,868 миллион кеше яши икән. 3 миллионга якын кеше – шәһәрдә, ә 914 меңе – авылда. Бер сукачыга дүрт тамак туры килә түгелме соң? Һаман артып баручы шәһәр халкын туйдырырга авылның көче җитәрме – монысын вакыт күрсәтер.

СКИФЛАР ҺӘМ КАЦАПЛАР

Россия гражданнарының милләтен үзенә билгеләү хокукы безнең тирәбездә ышанмаслык затлар яши башлауга китерде: хоббитлар, эльфлар, гоблиннар, марсианнар... Алар арасында тарихыбызга бәйлеләре дә бар: скифлар, русичлар, печенеглар, болгарлар, казаклар... Гражданнарыбызның бәйдән ычкынган «милли» фантазиясенә чик куярга карар кылынды. Өстә инде мөмкин вариантларның исемлеге дә бар. Тик аңа карап кына хәл үзгәрмәде. Толерантлык дигән нәрсә исемлеккә 1840 милләт кертелүенә китерде. Алар арасында иң көтелмәгәннәре: «дөнья кешесе», «совет кешесе», «кушылгак» һәм «кацап».

ЭЧӘРГӘМЕ, ЭЧМӘСКӘМЕ?

Күптән түгел швед микробиологлары рәсми рәвештә краннан аккан суны эчәргә ярый, дип белдерделәр. Мондый суның бер стаканында дистәләгән миллион бактерия яши, ләкин алар бөтенесе дә сәламәтлек өчен файдалы икән. Коммуникацияләрнең су белән контактта булган өслеге биоплёнка белән капланган, һәм бу зыянлы микробларга үрчергә бирми. Бәлки, Швециядәге сууткәргечләрдә бу шулайдыр да, тик менә бездәге краннардан кайчак бик шикле төстәге сыекча ага. Һәм анда файдалы бактерияләр мыжлап торуына үзеңне ышандыру бик кыен.



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Намусыңны югалткансың икән, аны “табылдыклар өстәле”ннән эзләп табармын димә.

Алмаз Хәмзин: Ходайдан да сорама, хаҗга баруың белән дә акланма, гаебеңне танып, тәүбәгә кил!

Р. Н.: Акчасы зур булса да, саранның абруе кечкенә.

А. Х.: Юмарт булып та, җүләргә санаулары бик мөмкин.

Р. Н.: Хакыйкатьне болганчык судан эзләүчеләр дә байтак.

А. Х.: Шуңа күрә эзләтүчеләр, хаклыкны таба алмасыннар дип, суны юри болгаталар.

Р. Н.: Җилдә дә аваз бар, ләкин ул сөйләшә белми.


А. Х.: Ярый әле җил сөйләшә белми, белсә нишләр идек, болай да инде ул давыллар куптара...

Р. Н.: Дураклар стресс һәм депрессия нәрсә икәнен белмәүләре белән “бәхетле”.

А. Х.: Алга киткән илләрдә яшәүчеләр безгә “Сез үзегезнең хәерче икәнлегегезне белмәвегез белән бәхетле”, – диләр. Димәк без...

Р. Н.: Дәртле хатынның сулышына хәтле кайнар була.

А. Х.: Рашат дус, бу өлкәдә үзеңнең специалист икәнеңне әйтеп тормасаң да була иде инде...



КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ



• • •

– Гаепләнүче, сез дөресен, бары тик дөресен сөйләргә һәм дөресеннән башка берни дә сөйләмәскә ант итәсезме?

– Ант итәм, мыеклы юан хатын.

Александр СЕРГЕЕВ





Александр КОСМЫЛИН

• • •

Гаепләнүче – адвокатка:

– Әгәр судья миңа бер елдан артык бирмәсә, миннән бер миллион.

Хөкем карары яңгырап, бер ел алгач, гаепләнүче адвокаттан сорый:

– Судьяны күндерү авыр булдымы соң?

– Бик авыр – ул сезне акларга теләгән иде...



Сергей АНДРИАНОВ

• • •

Судья:

– Халык арасында сезнең турыда карак диган сүз йөри.

– Һи-и, гражданин судья, халыкның һәр сүзен дөрескә саный башласаң, без сезнең белән икебез дә әллә кайчан төрмәдә утырасы кешеләр.



•••

Кызлар яратучы мәктәп укучысы көненә утызар портфель күтәреп йөргән.

•••

Мәктәптә яхшы укучы балаларның ата-аналары мәктәп программасын онытып бетермәгән.

Валентин ДУБИНИН






Валерий ТАРАСЕНКО



Николай ВОРОНЦОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Эрнест ДЫШАЕВ



Ринат БӘШИРОВ



"ТАШАТКЫЧ"

Чаян дус! Корал сату тыелганлыктан урамда атыш-мазар сизелми үзе. Ә менә машина атышына эләгергә дә мөмкин. Дөрес, көпшәдән булмаса да, кар җыю машинасы куркыныч тудыра.

Күптән түгел минем машинам да шундый атышка тап булды. Сөембикә һәм Вахитов урамы киселешендә кар җыючы зур йөк машинасы комлы катнашма өермәсе "Шевроле"мне күмеп китте. Ишектә һәм тәрәзәдә 3 китек һәм 4 тырналу санадым.

Ә менә таксист дустыма тагын да ныграк эләккән. Шамил Усманов урамында кар җыю тракторы атышына дучар булган "Приора" зур зарар күргән. Чистарткыч щеткадан ком түгел, ә таш һәм шешә ватыклары машинаның фарасын ваткан. Шәһәр күләмендә "юл атышы" корбаннарын санап бетерә торган түгел...

Күрәсең, кар көрәшендә "атыш" техникасының көчен көйләп булмый. Ә менә "ташаткыч" астында берәр коммуналь хуҗалык башлыгы машинасы калса, бу җайсызлык бик тиз көйләнер иде...

М. СӘФИУЛЛИН

ЧАЛЛЫ

КИБЕТ АША – БЕЛЕМГӘ!

Хөрмәтле редакция! Берничә ел элек Декабристлар урамы 89 нчы "а" йортында гимназия ачылган иде. Уку бинасын ничек кирәк, шулай матурладылар: зур койма белән әйләндереп алдылар, агачлар утырттылар, җәяүлеләр өчен уңайлы тротуар да ясадылар. Бик зур көч түгелде, ник дисәң дә, югары дәрәҗәле кунаклар чакырулы иде ачылыш тантанасына.

Мәктәп ачылып, ыгы-зыгы уткәч, әлеге мактаулы мәйданда төзелеш эшләре кабаттан кузгалды. Тротуар өстендә, мәктәптән ике адым да атламас борын, зур кибет төзелә башлады. Әйтерсең, кибетләр аз, шул тирәдә генә дә унлап сату нокталары урнашкан.

Хәзер исә мәктәпкә юл тоткан әтиәни һәм укучылар әлеге төзелешне машина юлыннан йөрергә мәҗбүрләр. Үз гомерләрен куркыныч астына куйган балаларның башка чарасы юк. Шулай да, әлеге кибет төзелгәч, аң-белем алырга зур кибет аша узачаклары аларга шактый бөек дәрәҗә һәм абруй өстәр инде...

Т. НУРМӨХӘММӘТОВА

КАЗАН

ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП



(Язучы-сатирик Камил Кәримовның 1999 елда “Чаян” журналында басылган мәкаләсеннән):

Барлык җырчыларны да берләштерә торган уртак хыяллар була – кызыл хыяллар. Мирсәет Сөнгатуллинның иҗади хыяллары белән егерме ел буе таныш инде мин.

1984 елның көзендә, консерваторияне тәмамлап, филармониягә эшкә килгән Мирсәетне лекторийлар бүлегенә беркетәләр. Шагыйрь белән музыкантка ияреп, мәктәпләрдә, клубларда җырлап йөрүләре “Опера һәм концерт җырчысы” дигән дипломы булган Әлки егетенә зур мәртәбә кебек тоелмагандыр, әлбәттә.

Балаларны җәйге каникулдан көч-хәл белән җыеп алган А. Алиш исемендәге Пионерлар сараена яшь шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм баянчы Алмаз Имаев белән Мирсәет десанты килеп төшә. Тагын 14 мәктәптә чыгыш ясыйсы бар, дигәч, Роберт ашыгыч рәвештә “Казан утлары” журналы эшләре белән командировкага китеп барды. Афишадагы яшь шагыйрь Роберт Миңнуллин булып, лекторий сәгатьләрен мин дәвам иттем. Исемемне сораган кеше юк – афишага ышаналар, басылган хикәяләремнең эчтәлеген русчалатып сөйләп бирәм, Робертның тәрҗемә шигырьләрен укыйсы урынга – курай уйныйм... Ә Мирсәет Сөнгатуллин, микрофонсыз-нисез 300 баланың шаулашуын җиңеп, татар халык җырларын, Роберт Миңнуллин шигырьләренә язылган җырларны башкара, маңкортлашкан буынны моң тоярга мәҗбүр итә!

Бу аның кызыл юллы беренче афишасы иде...

Армиядән кайтып, җырчылыкка укып йөргән арада Мирсәеткә 30 тулып өлгерә.

Татарстанның Мәскәүдәге кызыл концертларында хөкүмәт җырчысына әверелгән Вафирә Гыйззәтуллина бер Сергач кызы белән дуслаша. Кадриянең Мәскәүдә бер бүлмәле фатиры бар: ул искиткеч тыйнак, милли йолаларны хөрмәт итә; сәнгатьне өзелеп ярата; иң мөһиме – бай нәселдән. Булачак милли сәясәтче Вафирәнең яучылык таланты ачыла – Мирсәет белән Кадрия бер күрүдә гашыйк булалар. Кыз ягында һәм Мирсәет тарафыннан Казанның татар ашлары йортында җир тетрәтеп, олау-олау бүләккә күмелеп кызыл туйлар уза.

Ул елларда филармониядә эшләп фатир яисә мактаулы исем алу өчен “Кызыл кар” яуганны көтәргә кирәк иде. Мәскәүдә тамыр җәйгән Кадрия, туй күлмәкләрен кигән килеш, Казанның Калинин урамындагы тулай торакның кызыл почмагына кайтып төшкәч, мәдәният министры М. Таишев белән филармония директоры М. Таҗетдиновны ике ел буе очкылык тоткандыр. Һәм яшь гаилә 1987 елны Мәскәүгә күчеп китә. Ә бу инде рәсми тантаналарда “Кызыл җырларны” башкарырлык, “почти Илһам Шакиров” дип макталган тенорлы-баритон – Мирсәет Сөнгатуллин Мәскәү өлкә филармониясенең “Бәйрәм” төркемендә такмаклар җырлап йөрергә тиеш дигән сүз. Егетнең: “Фатир бирсәләр, Казанга кайтыр идем”, – дигән җан авазы өч ел буе Мәскәүдән сәлам булып ишетелә торды. Һәм, ниһаять, Казан аны ике бүлмәле фатир белән каршы алды.


Җырчының тагын бер хыялы тормышка ашты – ул бүген “Татарстанның халык артисты” дигән мактаулы исем алды. 100 дән артык җыр башкарып, алты аудио альбом чыгарган Мирсәет 1999 елга “99”лы “Жигули” белән җырлап килеп керде.

Әле аны алда яңа биеклекләр көтә.



Айдар УТӘГӘНЕВ, «Чаян» № 10, 1980

– Менә, үземә кирәк мехларны билгеләп чыктым!



Светлана ПРИВИНА, «Чаян» № 22, 1984

– Менә Атлант итеп эшкә алдык!

ЯРЛЫГА КӘҖӘ ДӘ СЫЕР

Евгений ОБУХОВ

БАЙКАЛ белән БОКАЛ

Директор кабинетына тыны беткән баш зоолог йөгереп керде:

– Ә безнең кәҗә тәкәсе... теге... ни!

– Йә Ходам! – дип авыр сулап куйды директор. – Яхшылап карадыгызмы? Бернинди дә эзләр юкмы?

– Юк, юк! Ни мөгез, ни тояк!

– Эх, минем ул юлбарысларга беркайчан да ышанычым булмады, ач ерткычлар!.. Ә безгә бит сәгать икедә телевидениедән килергә тиешләр: "Юлбарыс Байкал һәм Бокал исемле кәҗә тәкәсенең гомергә булмаган дуслыгы!" Беләсезме нәрсә, башка тәкә җибәрегез. Юлбарысның тамагы тук, төшергәнче генә түзәр әле!

Ун көннән баш зоолог тагын директор янына атылып керде:

– Кәҗә тәкәсе... тагын! Гел булмаган диярсең!

Директор сикереп торды:

– Тиз генә охшаган алмаш табыгыз, бүген бит бездә Би-Би-Си!..

Ике айдан зоолог директор машинасына каршы чыкты:

– Тагын тәкә юкка чыккан! Ә бездә таплылары бетте! Болай гына түгел, ә бөтенләй бетте! Блогерлар белән телевизионщиклар бер караганнан ук сизеп алачаклар!

– Ничек бетте?! – директор машина тәрәзәсеннән юлбарыс читлегенә йодрык күрсәтте. – Мөгез, таплысының фоторәсемен алыгыз да берәр җирән тәкәне буягыз!..


Бер атнадан зоолог тын гына директор кабинетына керде.

– Нәрсә, тагынмы? Вәт хайван, юкка гына юлбарысларны... – дип авызын ачты директор.

– Кайттылар... – диде карлыккан тавыш белән зоолог. – Бөтенесе дә, урманнан койма тишеге аша... Бокал – башлык урынына. Буялганнарының буяулары агып төшкән. Карарга куркыныч! Ә монда "Юлбарыс Байкал һәм Бокал исемле кәҗә тәкәсенең гомергә булмаган дуслыгы" Халыкара симпозиумы килде. Юлбарыс иртә белән үк читлектәге ояга кереп посты, борынын да күрсәтми!..

– Мин дә әйтәм бит: юлбарысларны юкка гына җәлләмим бит! Вәт хайван, ә, Бокалны әйтәм!.. Эх, әйдә, симпозиумга күрсәтергә башка юлбарыс эзлә!

Игорь КИЙКО





Ринат МИРЗАЯНОВ



Игорь КИЙКО



ЧуАр пресса

ЙӨЗ ҺӘМ КҮБРӘК

Яз житкәч, Мәскәүдә "Жиртрест" дип аталган затлы исемле кафе ачылачак. Ул 100 килограммнан югарырак үлчәмдәге кунаклар өчен исәпләнгән. Ризык алар өчен йөри торган лентада китереләчәк. "Жиртрест" кафесының хуҗасы Светлана Золотая керә торган җиргә үлчәү куймакчы. Артык килограммнар өчен бонуслар өстәләчәк. Россиянең юан кешеләр клубы башлыгы Сергей Назаровның мондый исемгә хәтере калган, шуңа күрә симез мәскәүлеләрне бу кафега бойкот игълан итәргә чакыра.

"АЛТЫН" АЧКЫЧ

Италиянең Падуя шәһәрендә гадәттән тыш вакыйга булган. Янгын сүндерүче частька шунда яшәүче хатын мөрәҗәгать иткән. Тик янгын сүндерергә дә, агачтан песи алырга да кирәк булмаган. Тугрылык каешының ачкычын югалткан яшь хатын янгын сүндерүчеләрдән шул каешны салдыруларын сораган. Бу – аның урта гасыр романнарын артык күп укуыймы, әллә кемгәдер тугры булып, үз көченә ышанычы җитмәүме – бу турыда бер сүз дә әйтелми.

МӘХӘББӘТ СЕЛФИЕ

Англияле Рэй Смитның Гиннесслар рекордлар китабына эләгергә мөмкинлеге бар. Океан буйлап кер үтүкли торган тактада да йөзмәгән, атна буе гамбургерлар да ашамаган, ә бары тик сөеклесенә тәкъдим генә ясаган. Биш ай эчендә ул 148 тапкыр аның кулын сораган. Һәр көнне Рэй, аңа кияүгә чыгуын сорап, үзенең фотографиясен җибәргән.

Виталий ФЕОКТИСТОВ




Александр АЛЁШИН




РЕКЛАМА

2016 елның беренче яртыеллыгына язылу дәвам итә.


Журналның индекслары татар телендә – 73488,
рус телендә – 73489




Интернетта безнең сайт: chayan-journal.ru



Клод СЕРРА (Франция)



Генрих БЮТНЕР (Германия)



Курт МЕНГЕ (Австрия)





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Оҗмах ишеге төбендә ике фәрештә.

– Менә тагын гөнаһлыларны җибәргәннәр! Кертмибез, аларның урыны тәмугта!

– Нишләп син алай әйтәсең – толерантно түгел бит? Гөнаһлылар түгел, ә альтернатив-хыянәтсезләр. Тәмугта түгел, ә альтернатив климатлы оҗмахта...

• • •

Электроника кибетенә сатып алучы керә. Шул мизгелдә аның янына сатучы-консультант пәйда була:

– Сезгә нинди дә булса киңәшфәлән кирәкмиме?

– Явыз Иван хакимлек иткән чорны әйтмәссезме?

– Юк шул...

– Пифагор теоремасын?

Консультант җилкәсен селкетеп куя.

– Фотосинтез?

– Әйтә алмыйм...

– Соң, шулай булгач, "Киңәшфәлән кирәкмиме?" дип, нигә мине йөдәтәсез?!

• • •

Ирләр! Узган елны үзенең кәҗәсен таба алмаучылар 2016 елда үзенең маймылын очрату мөмкинлеге бар. Һәм ашыгыгыз – 2017 елда сезне тавык көтә!

• • •

– Синең артык акчаң юкмы?

– Юк! Ул акчага ирек бирсәң – соңыннан кычкыртып та ала алмассың...

• • •

Авыл клубында дискотека бара. Бер егет бер кыз янына килә:

– Син биисеңме?

– Әлегә биемим.

– Алайса киттек – машинаны этәргә булышырсың!

• • •

– Синең йөзеңдә арыганлык чаткылары бар?

– Авырып алдым бит әле.

– Ә нигә табибка бармыйсың?

– Яшисе килгәнгә күрә.





САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН) № 3 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Алмаз ХӘМЗИН

Сәбәпсез көлү дә савыктыра

Узган гасырның җитмешенче елларыннан бирле галимнәр көлүнең файдасы турында тикшеренүләр алып баралар. Бу феномен белән кызыксыну бигрәк тә АКШ һәм Европа фәнни оешмаларын кузгатты. Төптәнрәк казынулар көлүнең кеше сәламәтлегенә һәм аның күңеле күтәрелүенә бик тә уңай тәэсир итүен ачыклады. Шул вакытлардан соң, фән, бу мәсьәләдә байтак тәҗрибә һәм мәгълүмат туплап, көлүнең дәвалау сыйфатларына зур әһәмият бирә башлады. Хәзерге вакытта дөньяда көлү терапиясе буенча байтак белгечләр эшли – аларны гелотоглар дип атыйлар.

Инде, мондый тикшеренүләр үткәргәнче үк, көлүнең кәефне һәм күңелне күтәрүен белә идек – хәтта көлгән вакытта гына да түгел, ә көне буена җитәрлек итеп. Фәнни термин кулланып әйтелгәндә, болай килеп чыга бу файдалы көлү: серотонин нейромедиаторлары һәм дофаминның, әле тагын эндорфинның аеруча күп биохимик рәвештә организмда бүленеп артуына бәйле икән ул. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, көлү – физик яктан үзеңне тәрбияләү нәтиҗәләренә – аэробик күнегүләр белән чагыштырырлык, ягъни 80 гә якын мускулларны киерә, иң өсләре күкрәк тирәләрен һәм диафрагманы дерелдәтә. Шул чагында муен мускулы, җилкә һәм бит киеренкелеге кими – менә шул баш авыртуын басарга мөмкин. Көлгән вакытта йөрәк тибеше ешая, һәм холестерин микъдары кими. Шуңа күрә кешенең сулыш алуы яхшыра, бу кислород белән тәэмин ителүгә уңай йогынты ясый, организмда кан йөрешен җайлый.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, көлү барлык авырулардан коткарырга мөмкин – психик һәм нерва бәлаләреннән генә түгел. Ул стресс гормоннары бүленеп чыгуын киметә, кан басымын камилләштерә, иммунитетны күтәрә. Тагын бер зур файдасы – көлеп яшәү йөрәк авыруы белән интегүчеләрне инфаркттан саклый. Онкология авырулары белән җәфаланганнарны савыктыру очраклары күзәтелгәне бар. Менә шундый күзәтүләрдән соң, бары бер фикергә киләсең – көлеп яшәргә кирәк.

Ләкин күбебез бик тә үзенчәлекле юмор эзлибез. Көләр өчен югары сыйфатлы юмор эзләп тилмерәбез. Кайберләребез әллә ничаклы анекдот белә. Кемнеңдер юмор хисе юк дәрәҗәсендә, һәм аны көлдерер өчен даһи мәзәкчеләрнең дә көче җитми. Мондый очракларда психотерапевтлар сәбәпсез көлү ысулын куллануны тәкъдим итә. “Карале, бер сәбәпсез көлеп утыра – җүләрдер ул”, – ди безнең халык. Ләкин медицина күзлегеннән карап әйткәндә, бу фикер дөрес түгел. Сәбәпсез көлеп утыру сәләтенә ия булу җан һәм физик яктан камиллекне генә аңлата. Бу – булдыклылык, шаяра һәм шаярта белүдән күпкә әһәмиятлерәк. Японияда Хотей дигән бер монах тирә-юньдәгеләрне эчләре катканчы көлдереп йөри торган була. Шулай итеп, ул күпләрне дәвалый алуына ышандыра алган. Әйе, бу риваять кенә түгел – чын дөреслек.


Безнең һәрберебез көнен гел көлеп кенә үткәрергә тырышып карасын: йокы алдыннан да, иртән иртүк тә. Иң яхшы нәтиҗәне сез йомык күз белән эшләп алырсыз.

Хәзерге заманда Европаның күп кенә илләрендә көлү үзәкләре ачылган, анда халык фитнес-клубка йөргән кебек килә. Монда халыкны тормышны яратып яшәргә өйрәтәләр: кояшлы һәм болытлы көнгә карап елмаерга, яңгырга һәм җилгә, сабый көлүенә һәм янәшәдән үтеп баручы кешегә якты йөз белән карарга. Бу эшне профессиональ психотерапевтлар гына алып бармаска да мөмкин. АКШта, мәсәлән, аны уңышлы рәвештә актер Чарльз Меткаф үткәрә. Ул үзенең дәресен гади генә күнегүдән башлый: басарга – сулыш алырга – көлергә. Меткаф әйтүенчә, бәхетсезлекнең яки уңышсызлыкларның килеп чыгарга мөмкинлеге мәгънәсезлек икәнен аңлаган булып көлү. Аннан соң ул һәрвакыт үзең белән клоун борынын алып йөрергә тәкъдим итә һәм аны көзге каршында яки кешеләр алдында киеп көлергә куша. Актер фикеренчә, бу алымнар сезне күпкә бәхетлерәк итәчәк.


Меткаф киңәшенә өстәп, мин дә сезгә, хөрмәтле укучылар, кулыгызга “Чаян” журналы да тотып йөрегез дип әйтәсем килә. Ул да һәр кешегә бу дөньяда көлеп кенә яшәргә ярдәм итәчәк.

Бу язмамның сихәте, һичшиксез, булачак дигән фикердә калам.

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Кышның беренче кагыйдәсе?

2. Ир кеше нинди булырга тиеш?

3. Автобуста барганда күңелсез булса һәм сөйләшәсегез килсә, нишләргә?

4. Ни өчен хастаханәдәге санитарлар нык һәм таза?

5. Тиз генә айнып өчен нишләргә кирәк?

6. Күңеленне ана мәче тырнаса, ни кылырга?

7. Сәрхушләрнең яраткан конфеты?

ҖАВАПЛАР

1. Әгәр дә барлык кошларның җылы якка киткәненә чынлап ышанмасаң, авызыңны ачып, кар бөртекләрен аулама. 2. Үзе өйләнгән маймылга караганда, бераз гына матуррак булырга. 3. “Илне нинди хәлгә төшерделәр!” дигән фраза әйтеп куярга. 4. Медицина спиртын витамин белән йотып куйганга күрә. 5. Көн саен үсә барган евро белән доллар курсын карап алырга. 6. Анда ата мәчене кертергә. 7. “Белочка”.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемнәрен укыгыз. Журналыбызның 1 нче санында басылган чаянвордның тикшеру сүзләре – **«БАЛАМИШКИН», «САКМАР».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Х. ГАБИТОВ (Арча р-ны, Иске Кишет ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Арчадан


Хәмбәл ГАБИТОВ!

Карикатура осталары

Виктор СКРЫЛЁВ (Россия)




Танылган совет һәм рус рәссамы Виктор СКРЫЛЁВ Одессада туган. Юмор белән дан казанган Одесса традицияләрен дәвам итеп, ул үзенең иҗатында төп нәрсә итеп карикатураны сайлаган. Илебездә аның рәсемнәре басылмаган бер генә басма да юктыр, мөгаен. «Чаян» да шулар рәтенә керә, әлбәттә.









4 612750 670080